КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 14 февраль г.Казань № 101

«Татарстан Республикасының Креатив индустрияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасын төзү турында

«Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясендә креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2024 елның 8 августындагы 330-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында креатив (иҗади) индустрияләрне үстерү турында» 2025 елның 26 апрелендәге 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында креатив икътисадның база секторы буларак креатив (иҗади) индустрияләрне оештыру һәм үстерү, Татарстан Республикасы территориясендә креатив индустрияләргә ярдәм итү инфраструктурасын булдыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының Креатив индустрияләрне үстерү үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасын (алга таба – Үзәк) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

Татарстан Республикасы исеменнән Үзәкнең гамәлгә куючылары булырга;

Үзәк идарәсе органнарына Татарстан Республикасы вәкилләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә;

60 көн эчендә Үзәк уставын расларга һәм аны Россия Федерациясе законна-

рында билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

2026 елның 30 апреленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 10,0 мең сум күләмендә ирекле мөлкәт кертемен тигез өлешләрдә кертергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин